**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
(IV чакырылыш)

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

28 нче декабрь 2023 ел **№ 229** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары (26.05.2014 № 210, 15.11.2016 № 67, 20.04.2017 № 84, 19.07.2017 № 90, 12.04.2018 № 127, 24.08.2018 № 141, 13.12.2018 № 160, 20.01.2020 № 224, 30.07.2020 № 246, 03.09.2020 № 248, 30.06.2021 № 63, 01.02.2023 № 171, 20.10.2023 № 210 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяда:

а) 5 өлешне «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

б) 7 өлешне «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 10 статьяда:

а) 7 өлештә «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 7.1 өлеш белән тулыландырырга:

«7.1. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.3. 14 статьяда:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чиннар бирү турындагы күрсәтмә кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

1.4. 31 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш белән тулыландырырга:

«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмаган яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм башкармаган өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса. .».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы

Н.Н. Хаҗипов